КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 ноябрь г.Казань № 980

2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган һәм, аларны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирелә торган чыгым йөкләмәләре, субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре һәм аларның мәгънәләре исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 139 статьясындагы 3 нче пункт, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.4 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу карарга теркәлгән 2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган һәм, аларны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирелә торган чыгым йөкләмәләре, субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре һәм аларның мәгънәләре исемлеген расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 3 ноябрь, 980 нче
карары белән расланды

2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган һәм, аларны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирелә торган чыгым йөкләмәләре, субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре һәм аларның мәгънәләре исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәсе исеме | Субсидия исеме | Дәүләт программасы кысаларында субсидия бирелә торган әлеге программа исеме | Нәтиҗәлелекнең максатчан күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Еллар буенча максатчан күрсәткеч мәгънәсе<*> | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы | | | | | | | | |
| 1.1 | Мәгариф өлкәсендә яшь белгечләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар | Мәгариф оешмаларында педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыра торган өстәмә акча түләү өчен субсидия | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы | ай саен стимуллаштыра торган өстәмә акча түләнгән педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләрнең норматив хокук актлар нигезендә түләү каралган педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләрнең гомуми санындагы өлеше | процент | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. | Һәркем файдалана ала торган муниципаль китапхәнәләрнең китап фондларын комплектлау | Мәдәният тармагына булышлык күрсәтү өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы | китапханәләрдә булулар саны (бер елга 1 яшәүчегә) | булу | 4 | 4 | 4 |
| 2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы | | | | | | | | |
| 2.1 | Мәгариф өлкәсендә яшь белгечләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар | Мәгариф оешмаларында педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыра торган өстәмә акча түләү өчен субсидия | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы | ай саен стимуллаштыра торган өстәмә акча түләнгән педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләрнең норматив хокук актлар нигезендә түләү каралган педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләрнең гомуми санындагы өлеше | процент | 100 | 100 | 100 |
| 3. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы | | | | | | | | |
| 3.1 | Муниципаль берәмлектә яшәүче һәм торак урыннарга мохтаҗ булучы аз керемле гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү, муниципаль торак фонды төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак тикшерүен, шулай ук җирле үзидарә орган- | Яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирү өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасы | чираттагы елда торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле яшь гаиләләрнең бу категориядәге мохтаҗ булучыларның гомуми санындагы өлеше | процент | 2,4 | 2,3 | 2,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | нарының башка вәкаләтләрен торак законнары нигезендә гамәлгә ашыру | | | | | | | |
| 3.2. | Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм савыктыруын оештыру чаралары | Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы | балаларны һәм яшьләрне ял итүнең оештырыл-ган формалары белән җәлеп итү | мең кеше | 145 | 145 | 145 |
| 4. Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | | | | | | | | |
| 4.1 | Муниципаль берәмлектә яшәүче һәм торак урыннарга мохтаҗ булучы аз keremле гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү, муниципаль торак фонды төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзеешe өчен шартлар тудыру, муниципаль торак тикшерүен, шулай ук җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен торак законнары нигезендә гамәлгә ашыру | Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту өчен субсидия | «2013 – 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын җайга салу» дәүләт программасы | авыл җирлегендә яшәүче гражданнар өчен торакны кулланышка тапшыру (сатып алу) | кв.метр | 9 907 | 14 311 | 17 891 |
| 4.2. | Муниципаль берәмлекләр халкы массакүләм ял итү һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын | Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның җирле инициативаларына грант | «2013 – 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукция- | авыл җирлегендә яшәүче, грант ярдәмен алган гражданнарның җирле инициативаларының | берәмлек | 2 | 3 | 4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җайлаштыруны оештыру өчен шартлар тудыру (гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буйларыннан иркле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп) | белән ярдәм күрсәтү өчен субсидия | се, чималы һәм азык-төлек базарын җайга салу» дәүләт программасы | тормышка ашырылган проектлар саны | | | | |
| 5. Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы | | | | | | | | |
| 5.1 | Мәгариф өлкәсендә яшь белгечләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар | Мәгариф оешмаларында педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыра торган өстәмә акча түләү өчен субсидия | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы | ай саен стимуллаштыра торган өстәмә акча түләнгән педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләрнең норматив хокук актлар нигезендә түләү каралган педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләрнең гомуми санындагы өлеше | процент | 100 | 100 | 100 |
| 5.2. | Балалар белән мәктәптән тыш эшләү учреждениеләрендә эшләүче тренер-укытучыларга һәм спортчы-инструкторларга ярышларда югары нәтиҗәләргә ирешкәне өчен ярдәм | Балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирә торган муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче тренер-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы | спортчылар әзерләгән һәм ярышларда югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен түләүләр алучы тренер-укытучылар һәм спортчы-инструкторлар саны | кеше | кимендә 300 | кимендә 300 | кимендә 300 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар | шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру чарасы түләүгә субсидия | | | | | | |
| 5.3. | Балалар-үсмерләр спортын үстерү | Балалар-үсмерләр спорт мәктәпләре, шулай ук физик культура өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яңадан ачыла торган спорт объектлары һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмалары өчен спорт җиһазлары, инвентаре һәм форм-алары сатып алу өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы | субсидияләрнең муниципаль берәмлекләр тарафыннан факттагы үзләштерелү дәрәҗәсе | процент | 100 | 100 | 100 |
| 5.4. | Балалар-үсмерләр спортын үстерү | Алкалы хоккей буенча балалар-үсмерләр спорт мәктәпләрен һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең эшләп торучы боз сарайлары каршындагы балалар-үсмерләр спорт мәктәпләренең алкалы хоккей бүлекләрен үстерү өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең эшләп торучы боз сарайлары каршындагы хоккейны үстерүгә субсидия алган хоккей буенча муниципаль спорт мәктәпләренең (бүлекләренең) әлеге хоккей буенча учреждениеләрнең (бүлекләрнең) го- | процент | 100 | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | муми санындагы өлеше | | | | |
| 6. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы | | | | | | | | |
| 6.1 | Муниципаль район составына керә торган җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү һәм бюджетларына башка төрдәге бюджетара трансфертлар бирү | Муниципаль район составына керә торган җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү һәм бюджетларына башка төрдәге бюджетара трансфертлар бирү өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасы | бюджет тәэмин ителешен тигезләү-гә дотацияләр һәм башка төрдәге бюджетара трансфертларның гомуми күләмендә муниципаль район бюджетыннан муниципаль район составына керә торган җирлекләр бюджетларына үз вакытында һәм тулы күләмдә бирелгән бюджетара трансфертларның күрсәтелгән төрләре чагыштырма авырлыгы | процент | 100 | 100 | 100 |
| 6.2 | Муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем файдалана алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, муниципаль белем бирү оешма- | Муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем файдалана алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, муниципаль белем бирү | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасы | муниципаль белем бирү оешмаларын норматив финанслауны тәэмин итү | процент | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тору һәм тәрбияләү, карау өчен шартлар тудыру, шулай ук каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру | оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тору һәм тәрбияләү, карау өчен шартлар тудыру, шулай ук каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру өчен субсидия | | | | | | |
| 7. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | | | | | | | | |
| 7.1 | Биологик калдыкларны җыю, саклау һәм чыгару буенча чаралар | Биологик калдыкларны җыю, саклау һәм чыгару буенча чаралар оештыру өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы | муниципаль берәмлек территориясеннән җыелган һәм чыгарылган биологик калдыклар саны | тонна | 120 | - | - |
| 8. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы | | | | | | | | |
| 8.1. | Территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләре | Территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен бирү өчен субсидия | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы | җитәкчеләргә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтелгән территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны | берәмлек | 329 | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән |

<*> Муниципаль бермәлекләр яктылыгында субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең аерым максатчан күрсәткечләре мәгънәләре Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчеләр тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль берәмлекләргә җибәрелә.

---